Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2019 елның 28 ноябре №26

«Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Янил авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Янил авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Янил авыл җирлеге Советы карарына (Янил авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 42 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 25 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 16 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 14 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 32 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 37 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 39 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кадастр бәясеннән 0,1 процент – торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Янил авылы җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге Башлыгы И.Х.Корбанов

СОВЕТ ЯНИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893